РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
СОВЕТ ИЗМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
422052, Республика Татарстан,
Сабинский район,
с.Измя, ул. Школьная, 9
тел. (84362) 49-1-32, 49-1-22

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЭЗМӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422052, Татарстан Республикасы,
Саба районы,
Эзмә авылы, Мәктәп урамы, 9 йорт
тел. (84362) 49-1-32, 49-1-22

e-mail: Izm.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
23.10.2024

КАРАР
№14

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге Советының 26.11.2019 елгы 31 номерлы «Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә һәм федераль законнарның үзгәрүенә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Эзмә авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге Советының «Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» 26.11.2019 елның №31 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2. пунктның 1.2.2. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2.2. торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегенең өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш, эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләрен һәм аларның һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган җир кишәрлекләрен;»;

1.2. 1.2. пунктның 1.2.3. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2.3. шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган, шулай ук "гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләре, моңа һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән җир кишәрлекләренең әлеге абзацында;».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/izma адресы буенча рәсми рәвештә бастырып чыгарырга һәм җирлекнең махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакытыннан үз көченә керә.

Эзмә авыл
җирлеге Башлыгы

Р.Г. Ахметов